**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советын төзү турында» 2010 елның 31 декабрендәге ПУ-908 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 30 апрелендәге ПУ-247 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 2 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2018 елның 14 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-369 номерлы, 2019 елның 2 февралендәге ПУ-59 номерлы, 2019 елның 21 августындагы ПУ-479 номерлы, 2019 елның 25 ноябрендәге ПУ-707 номерлы, 2021 елның 14 гыйнварындагы ПУ-3 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 16 маендагы 302 номерлы, 2023 елның 25 августындагы 589 номерлы, 2024 елның 18 гыйнварындагы 26 номерлы, 2024 елның 30 мартындагы 229 номерлы һәм 2024 елның 15 августындагы 623 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Инвалидлар эшләре советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан З.Р. Вәлиеваны, И.В. Волынецны, Р.Р. Гайзатуллинны, В.М. Гаулстонны, М.М. Миңнуллинны, Р.Н. Садыйковны чыгарырга;

б) Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Абашев Альмир Рәшит улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Доронина Ирина Александровнаны – «Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика бүлекчәсе рәисен (килешү буенча);

Кадыйров Азат Рифгать улын – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрын;

Созинов Алексей Станиславовичны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисен (килешү буенча);

Терентьев Александр Михайловичны – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улын – Татарстан Республикасы финанс министрын;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

С.М. Захарованың – «Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча)»;

Е.Г. Кабышның – «Әфганстан һәм махсус хәрби операцияләр ветераннарының Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 13 март
№ 199